КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 декабрь г.Казань № 1119

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге «Голубые озера» комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2003 ел, 16 июнь, 324 нче карары белән расланган Төбәк әһәмиятендәге «Голубые озера» комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге «Голубые озера» комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2003 ел, 16 июнь, 324 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 20 февраль, 80 нче; 2011 ел, 14 апрель, 295 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 2 апрель, 259 нчы; 2015 ел, 15 апрель, 253 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1223 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 930 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк әһәмиятендәге «Голубые озера» комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.1 нче пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак пунктлардан тыш, коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәтләреннән тыш һәм коммерцияле булмаган яшелчәчелек ширкәтләреннән тыш, хуҗалык, сәнәгать объектлары, коммуналь объектлар, индивидуаль торак төзелеше объектлары, блоклы торак йортлар төзелеше һәм тыюлык эшчәнлегенә һәм урман хуҗалыгын алып баруга

бәйле булмаган башка корылмалар төзү һәм урнаштыру (элек төзелгән объектларны реконструкцияләүдән тыш);»;

10.1 нче пунктны түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«индивидуаль торак төзелеше өчен (торак пунктлар чикләрендә) (2.1);

блоклы торак йортлар төзелеше (торак пунктлар чикләрендә) (2.3);

автотранспортны саклау (торак пунктлар чикләрендә) (2.7.1).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин